# Җәлилнең кадерлеләре

# Хатыны Әминә



**Хуш, акылллым!**

**Соңгы минутта да**


**Мин уйлармын синең турында;**

**Уйлар минем туңган күкрәгемне**

**Җылытырлар синең куеныңда.**



# Кызы Чулпан





*Кеп-кечкенә булып туган иде,*
*Хәзер сизәм көн дә артуын.*
*Күргән саен шуны,йөрәгемдә*
*Дулкынланып таша шатлыгым.*

# Әминә,Чулпан,Таня,Миша



# Чулпан оныгы Миша белән

## ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ...

Китаплар актарганда, тышына алтын сары яфраклар төшкән әллә кайчангы иске блокнотым килеп чыкты. Кызык итеп, битләрен ачкалап карый башладым. Өзек-төтек җөмләләр, кыскартып язылган сүзләр, төрле исемнәр, даталар... Менә бу биткә Ломоносов проспекты, «Университет» станциясе дип язып куйганмын. Бу бит Әминә Җәлилова адресы!

...1984нче елның март башында мине Мәскәүгә командировкага җибәрделәр. Журналның баш редакторы Роза апа Хафизова миңа шундый задание бирде: Муса Җәлилнең хатыны Әминә апа, кызы Чулпан, оныгы Таня белән очрашып, журналның 60 еллык юбилей саны өчен материал әзерләп кайтырга. (Таня ул чакта нәкъ «Ялкын» укучы кызлар-малайлар яшендә иде. — **Э.З.**) Бәлки, Җәлилнең оныгы исеменнән оештырырсың материалны, диде. Миңа журналда бер бит бирелгән иде. Телефон, адреслар белән Рафаэль абый Мостафин ярдәм итте. Мәскәүгә шалтыратып, барасы көнемне алдан ук хәбәр итеп куйдым. Ә Мәскәүгә килгәч инде вокзалдан туп-туры Ломоносов проспектына — Әминә Җәлиловаларга китүем хәтердә. Бераз борчылам, дулкынланам. Ничегрәк кабул итәрләр? Менә алар үзләре дә: фотолар аша таныш Әминә, Чулпан. Бик җылы каршыладылар! Әминә апа чәй табыны әзерләгән!

Кечкенә Мусаны хәтерләтүчесе — Таня. Кара чәчләр, коңгырт күзләр, бераз кысыла төшкән күз уемнары... Уйларымны сизгәндәй, Чулпан: «Безнең Таня бик музыкаль. Ул шул ягы белән дә әтигә охшаган, — ди. — Әти мандолинада уйнаган, җырлар иҗат иткән, «Алтынчәч» либреттосын язган... Мине дә музыкага өйрәтәсе бик килгән. Туган көнемә пианино алып бирергә хыялланган...»



*Муса Җәлилнең кызы Чулпан оныгы Миша белән. Мәскәү, 2006 ел, февраль.*

*МАРАТ фотосы*

# Таня улы Миша белән



# Муса Җәлил һәм Рауза Хисмәтуллина



# Муса Җәлилнең улы –Альберт Җәлилов

